# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең аерым мәсьәләләре турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 26 апрелендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон "Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең аерым мәсьәләләре турында" 2011 елның 7 февралендәге 6-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең контроль-хисап органнарын (алга таба – контроль-хисап органы) оештыруны һәм аларның эшчәнлеген федераль законнарда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә хокукый җайга салуны гамәлгә ашыра.

2 статья. **Контроль-хисап органы рәисе, рәисе урынбасары, аудиторлары вазыйфаларын муниципаль вазыйфаларга кертү тәртибе**

1. Контроль-хисап органы рәисе Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең вәкиллекле органының норматив хокукый акты нигезендә муниципаль вазыйфа били.

2. Контроль-хисап органы рәисе урынбасары, аудиторлары вазыйфалары Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының норматив хокукый акты белән муниципаль вазыйфаларга кертелергә мөмкин.

3 статья. **Контроль-хисап органы вазыйфаи затлары тарафыннан контроль-хисап органы рәисенә хәбәр итү тәртибе һәм формасы**

1. Контроль-хисап органы вазыйфаи затлары, Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында каралган очракта кассаларны, кассаны һәм хезмәт урыннарын, складларны һәм архивларны мөһерләп бикләп куйган, документлар һәм материаллар алган очракта, бу хакта әлеге Законга кушымта нигезендәге форма буенча кичекмәстән (24 сәгать эчендә) контроль-хисап органы рәисенә язма рәвештә хәбәр итәргә тиеш.

2. Контроль-хисап органы рәисенә әлеге статьяда билгеләнгән срокта язма хәбәрне тапшыру мөмкин булмаган очракта, соңыннан язмача хәбәр итү шарты белән, мөмкин булган бүтән алым белән хәбәр ителә.

4 статья. **Контроль-хисап органы гарызнамәләре буенча мәгълүмат тапшыру срогы**

1. Үзләренә карата контроль-хисап органы Федераль закон нигезендә тышкы муниципаль финанс контроле башкарырга хокуклы органнар һәм оешмалар (алга таба – тикшерелә торган органнар һәм оешмалар), аларның вазыйфаи затлары контроль-хисап органы гарызнамәсе буенча контроль һәм эксперт-аналитик гамәлләр уздыру өчен кирәкле мәгълүматны, документларны һәм материалларны гарызнамә алынган көннән 14 эш көне эчендә тапшырырга тиеш.

2. Контроль-хисап органы муниципаль берәмлек башлыгы тәкъдимнәре һәм гарызнамәләре, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы кушулары нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Хисап палатасының Татарстан Республикасы Президенты тәкъдимнәре һәм гарызнамәләре, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы кушулары нигезендә контроль һәм эксперт-аналитик гамәлләр уздыру кысаларында җибәрелгән мөрәҗәгатьләре буенча контроль һәм эксперт-аналитик гамәлләр уздырылган очракта, әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән срок җиде эш көненнән кимрәк итеп билгеләнергә мөмкин.

5 статья. **Контроль-хисап органы акты буенча аңлатмалар һәм искәрмәләр җибәрү срогы**

Контроль гамәлләр уздырганда контроль-хисап органнары тарафыннан төзелгән актлар тикшерелә торган органнар һәм оешмалар җитәкчеләренә җиткерелә. Тикшерелә торган органнар һәм оешмалар җитәкчеләренең җиде эш көне эчендә тапшырылган аңлатмалары һәм искәрмәләре актларга кушып куела һәм киләчәктә аларның аерылмас өлеше була.

6 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2012 елның 17 мае
№ 21-ТРЗ

"Татарстан Республикасы
муниципаль берәмлекләренең
контроль-хисап органнарын оештыруның һәм
аларның эшчәнлегенең аерым мәсьәләләре турында"
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

______________________________________
(контроль-хисап органының исеме)
____________________________________рәисе

______________________________________
(контроль-хисап органы рәисенең фамилиясе, инициаллары)

**Кассаларны, касса һәм хезмәт урыннарын, складларны һәм архивларны мөһерләп биклэп кую, документларны һәм материалларны алу турында**
**ХӘБӘРНАМӘ**

________________________________________________________________карата
(тикшерелә торган органның яисә оешманың исеме һәм адресы)

____________________________________________________контроль гамәл уздырганда
(контроль гамәл исеме)
"Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында" Федераль законның 14 статьясы һәм "Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең аерым мәсьәләләре турында" Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы нигезендә мин, ______________________________________

______________________________________________________________________,
(контроль-хисап органы вазыйфаи затының вазыйфасы, фамилиясе, инициаллары)

түбәндәгеләрнең мөһерләп биклэп куелуы (алынуы) турында Сезгә хәбәр итәм:

______________________________________________________________________
(мөһерләп биклэп куелган объектларның, алынган документларның һәм материалларның исемлеге)

Мөһерләп биклэп кую (алу) вазыйфаи зат катнашында башкарылды ____________________

______________________________________________________________________
(тикшерелә торган органның яисә оешманың исеме, тикшерелә торган орган вазыйфаи затының вазыйфасы, фамилиясе, инициаллары)

Объектларны мөһерләп биклэп кую (документларны һәм материалларны алу) факты буенча акт (актлар) төзелде, күчермәсе (күчермәләре) ______ биттә _____ нөсхәдә кушымта итеп бирелә.
"___" сәг. "___ " мин.

20__ елның "___" ____________ _____________________________________________
(контроль-хисап органы вазыйфаи затының имзасы, фамилиясе, инициаллары)